ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.11.2019 Казан шәһәре № 5-78/тэ

"РСК" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятеннән кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) 2020 елга тарифлар билгеләү хакында

"Җылылык белән тәэмин итү турында" 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында" 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карарына, Федераль тарифлар хезмәтенең "Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында" 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгына, Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының "2033 елга кадәр Казан шәһәре муниципаль берәмлеген җылы белән тәэмин итүнең актуальләштерелгән схемасын раслау турында" 2018 елның 16 августындагы 658 номерлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. "РСК" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – "РСК" ҖЧҖ) тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә), шушы карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2020 елның 1 гыйнварыннан башлап 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасының Тарифлар
буенча дәүләт комитетының 27.11.2019
ел, № 5-78/тэ карарына кушымта

"РСК" ҖЧҖ тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2020 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынулы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукция-ләштерелгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 $кг/см^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 $кг/см^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 $кг/см^2$ кадәр | 13,0 $кг/см^2$ югары | |
| | Казан шәһәре | | | | | | | |
| 1 | "РСК" ҖЧҖ | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 1520,45 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 1584,73 | - | - | - | - | - |
| 1.2 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)* | | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 1824,54 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 1901,68 | - | - | - | - | - |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын үтәү максатларында аерып чыгарыла

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге